КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 март г.Казань № 155

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 140 нчы карары белән расланган Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 август, 891 нче; 2023 ел, 17 июль, 850 нче; 2024 ел, 16 май, 324 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацында «кадәрге елда» сүзләрен «кадәрге кимендә ике елга кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «(алга таба – хисап финанс елы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.14 пунктның алтынчы абзацында «хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларының» сүзләрен «әлеге Тәртиптә каралган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия бирелмәгән очракта, агымдагы финанс елына кадәрге кимендә ике елга кадәр һәм (яисә) агымдагы финанс елында башкарылган» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктта:

уналтынчы абзацта «хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында» сүзләрен «агымдагы финанс елына кадәрге кимендә ике елга кадәрге чорда һәм (яисә) агымдагы финанс елында» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацта «хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында» сүзләрен «агымдагы финанс елына кадәрге кимендә ике елга кадәрге чорда һәм (яисә) агымдагы финанс елында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин